ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

12 гыйнвар 2018 ел. № 94

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими рәвештә йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 310 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законның 16 маддәсе, Татарстан Республикасының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» Татарстан Республикасы Законының 1 һәм 8 маддәләренә үзгәрешләр кертү хакында» 2016 елның 9 июлендәге 59-ТРЗ санлы Законының 1 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнен 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә даими рәвештә йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибен раслау турында» 2017 елның 26 гыйнварындагы 310 нчы карарына (Башкарма комитетның 2017 елның 15 февралендәге 769 нчы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) исемне «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә» сүзләреннән соң «һәм шәһәр яны элемтәсендә» сүзләре белән тулыландырырга;

2) преамбулада «2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ санлы Законының 3 маддәсенә» сүзләрен «2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ санлы Законының 4 маддәсенә» сүзләренә алмаштырырга;

3) 1 пунктны «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә» сүзләреннән соң «һәм шәһәр яны элемтәсендә» сүзләре белән тулыландырырга;

4) кушымтаны әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин

Башкарма комитетның
2018 елның 12 гыйнварындагы
94 нче карарына
кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә
һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрне
планлаштыру документын әзерләү
тәртибе

1. Әлеге тәртип «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ санлы Федераль закон, Татарстан Республикасының «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законны гамәлгә ашыру турында» 2015 елның 26 декабрендәге 107-ТРЗ санлы Законы, Татарстан Республикасының «Яр Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең җирле үзидарә органнарына халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру өлкәсендә дәүләт вәкаләтләрен бирү турында» 2006 елның 28 апрелендәге 32-ТРЗ санлы Законы, шәһәр Уставы, Шәһәр Советының «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясе чикләрендә автомобиль транспортында һәм җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру тәртибен раслау турында» 2015 елның 28 декабрендәге 5/7 нче карары нигезендә эшләнде һәм Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрне планлаштыру документын (алга таба – Планлаштыру документы) әзерләгәндә үтәлергә тиешле төп таләпләрне билгели.

2. Планлаштыру документын әзерләү максатлары булып түбәндәгеләр тора:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтүне оештыру;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими йөртүләрне үстерү юнәлешләрен билгеләү;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтү сыйфатын һәм нәтиҗәлелеген күтәрү.

3. Планлаштыру документы түбәндәгеләр турындагы мәгълүматны үз эченә ала:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә һәм шәһәр яны элемтәсендә гомуми файдаланудагы транспортта даими рәвештә йөртүләрне планлаштыруның максатлары һәм бурычлары;

2) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә һәм шәһәр яны элемтәсендә транспорт хезмәте күрсәтү системасының агымдагы торышы;

3) муниципаль маршрутларда, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутларда даими рәвештә йөртүләрнең төрен үзгәртүне планлаштыру;

4) муниципаль маршрутларны, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутларны билгеләү, үзгәртү һәм гамәлдән чыгаруны планлаштыру;

5) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә һәм шәһәр яны элемтәсендә транспорт системасын үстерүнең өстенлекле юнәлешләре.

4. Планлаштыру документы гомуми файдаланудагы транспортта йөртү эшчәнлеген регламентлаштыра торган норматив хокукый документларны исәпкә алып әзерләнә.

5. Планлаштыру документын әзерләү процессында Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүче муниципаль маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыручы юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең тәкъдимнәре исәпкә алынырга мөмкин.

6. Планлаштыру документы өч елдан ким булмаган срокка эшләнә.

7. Планлаштыру документына үзгәрешләр кертү Башкарма комитет карары белән гамәлгә ашырыла.

8. Планлаштыру документы әлеге тәртипкә кушымтада бәян ителгән структура нигезендә эшләнә.

9. Планлаштыру документындагы мәгълүматлар ачык һәм һәркем укый алырлык булып санала һәм вәкаләтле орган тарафыннан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында үз вакытында урнаштырыла һәм яңартыла.

Башкарма комитет
Аппараты Җитәкчесе

Г.К. Әхмәтова

Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрне планлаштыру документын әзерләү тәртибенә кушымта

Планлаштыру документының структурасы

1. Планлаштыру документы биш бүлектән тора:

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр;

2 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрнең агымдагы торышы һәм аларны оештырудагы проблемалар;

3 бүлек. Муниципаль маршрутларда, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутларда даими рәвештә йөртүләрнең төре;

4 бүлек. Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрне үстерү буенча чаралар исемлеге;

5 бүлек. Йомгаклау нигезләмәләре.

2. 1 нче «Гомуми нигезләмәләр» бүлегендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрне үстерү юнәлешләре, максатлары һәм бурычлары күрсәтелә.

3. 2 нче «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрнең агымдагы торышы һәм аларны оештырудагы проблемалар» бүлегендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегендә һәм шәһәр яны элемтәсендә халыкка транспорт хезмәте күрсәтү системасының агымдагы торышы: җәмәгать транспортының төре, маршрут челтәре, муниципаль маршрутлар, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутлар буенча пассажирлар йөртүне гамәлгә ашыра торган оешмалар;

2) даими рәвештә йөртүләрне оештырудагы һәм алар белән идарә итүдәге проблемалар.

4. 3 нче «Муниципаль маршрутларда, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутларда даими рәвештә йөртүләрнең төре» бүлегендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) планлаштыру документын раслау вакытына муниципаль маршрутлар, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутлар өчен билгеләнгән даими рәвештә йөртүләрнең факттагы төре (җайга салына торган тарифлар буенча / җайга салынмый торган тарифлар буенча);

2) муниципаль маршрутларда, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутларда даими рәвештә йөртүләрнең төрен үзгәртү мөмкинлеге турында мәгълүмат.

5. 4 нче «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә һәм шәһәр яны элемтәсендә даими рәвештә йөртүләрне үстерү буенча чаралар исемлеге» бүлегендә түбәндәгеләр күрсәтелә:

1) маршрут челтәрен формалаштыру буенча бурычлар;

2) транспорт инфраструктурасын, даими рәвештә йөртүләр белән идарә итү һәм аларның гамәлгә ашырылуын контрольдә тоту системасын камилләштерү буенча бурычлар;

3) даими рәвештә йөртүләрнең төрен үзгәртү, муниципаль маршрутларны, шәһәр яны элемтәсендәге маршрутларны үзгәртү һәм гамәлдән чыгару белән бәйле чараларны үткәрү сроклары (датасы).

6. 5 нче «Йомгаклау нигезләмәләре» бүлегендә даими рәвештә йөртүләрне үстерү буенча чараларны тормышка ашырудан көтеләчәк нәтиҗәләр күрсәтелә.